БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 12 2022 ел № 341

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләү «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 маендагы 124-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтына (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «02» 12 ______
341 ______ номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосаларын һәм бүлү полосаларын (алга таба - җирле әһәмияттәге автомобиль юллары) билгеләү тәртибен һәм алардан файдалануның махсус режимын билгели.

2. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлының бүлү полосасы чикләре территорияне планлаштыру документациясе нигезендә билгеләнә. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын һәм (яисә) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияне планлаштыру документларын әзерләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган җирләрне әлеге объектларны урнаштыру өчен бүлеп бирү нормаларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлын урнаштыру максатларында җир кишәрлекләре төзү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын балансta тотучы тарафыннан башкарыла.

4. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосалары киңлеге территориаль планлаштыру документларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияне планлаштыру документларында исәпкә алына.

5. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның аерым режимы билгеләнә, ул гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл буйларында капиталь корылмалар төзүнең тыелуын күздә тота, моңа түбәндәгеләр керми:

мондый автомобиль юлларына хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән объектлар, аларны төзү, реконструкцияләү, аларга капиталь ремонт ясау, ремонт ясау һәм карап тоту;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе объектлары;

юл сервисы объектлары, реклама конструкцияләре, мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләре;

инженерлык коммуникацияләре.

6. Юл сервисы объектларын, чиктәш урыннарны, мәгълүмат конструкцияләрен һәм күрсәткечләрен, инженерлык коммуникацияләрен һәм башка корылмаларны, автомобильләр туктап тору урыннарын (алга таба - объектлар) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә урнаштыру түбәндәге таләпләрне үтәгәндә рөхсәт ителә:

а) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында урнашкан җир кишәрлекләрендә, әлеге полосалардан читтә урнашкан, әмма җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында аларга махсус керүне урыны (керү урыннары, төшү урыннары, чиктәш урыннар) булуны таләп итүче җир кишәрлекләрендә объектларны урнаштыруга әлеге Тәртип белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) язмача ризалыгы булу;

б) вәкаләтле орган тарафыннан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә объектлар урнаштыру өчен җир кишәрлеге бирү;

в) объектлар урнаштыру урынын сайлау җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын реконструкцияләү мөмкинлеген исәпкә алып гамәлгә ашырылган;

г) объектлар урнаштыру, проектлау һәм төзү юл хәрәкәте иминлегенең, экологик иминлекнең, автомобиль юлларын төзүнең һәм эксплуатацияләүнең стандартлары һәм техник нормалары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш;

д) объектлар җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында күрү мөмкинлеген һәм юл хәрәкәте иминлегенең һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын эксплуатацияләүнең башка шартларын начарайтмаска, шулай ук халыкның куркынычсызлыгына янамаска тиеш;

е) юл сервисы объектлары җирле әһәмияттәге автомобиль юлыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, транспорт чараларын куеп тору урыннары һәм туктап тору урыннары, шулай ук керү, төшү урыннары һәм чиктәш урыннар белән җиһазландырылган булырга тиеш. Автомобиль юлы җирле әһәмияттәге автомобиль юлына тоташканда, керү урыннары һәм төшү урыннары юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, күчеш-тизлек полосалары белән җиһазландырылырга һәм автомобиль юлын төзекләндерүнең элементлары белән тәртипкә китерелгән булырга тиеш;

ж) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына тоташучы автомобиль юлларында, керү урыннарында, төшү урыннарында тоташкан урыннардан башлап күләме норматив документларда билгеләнгән күләмнән ким булмаган ераклыкка кадәр каты өслек булырга тиеш:

комлы, комсу һәм җиңел балчык туфрак булганда - 100 метр дәвамында;

кара туфрак, кызыл балчыклы, авыр һәм тузанлы балчыклы туфрак булганда - 200 метр;

з) авыл хуҗалыгы техникасының хәрәкәт итү маршрутлары җирле әһәмияттәге автомобиль юллары белән кисешү урыннарында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру белән төшү урыннары төзүне күздә тоту зарур. Төшү урыннарын урнаштыру урыннарын билгеләү, транспорт чаралары хәрәкәтен оештыру буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру кызыксынган оешмалар тарафыннан Башкарма комитетның язма формадагы ризалыгы белән башкарыла. Авыл хуҗалыгы техникасы хәрәкәт итү өчен I - II категориядәге автомобиль юлларыннан төшү урыннары төзү тыела. III - IV категориядәге автомобиль юлларыннан төшү урыннары арасындагы ераклык кимендә 2 км булырга тиеш, төшү урыннарында тоташкан урыннардан башлап күләме норматив документларда билгеләнгән күләмнән ким булмаган ераклыкка кадәр каты өслек булырга тиеш;

и) углеводород чималы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар объектларын төзү, ремонтлау, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында, шулай ук углеводород чималын җир асты байлыкларыннан башка төрле файдалану максатларында, (алга таба - җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында съездлар) техника хәрәкәте өчен II - IV категориядәге автомобиль юлларыннан төшү урыннары төзү әлеге пунктчада билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, IV категориядәге автомобиль юлларына куела торган таләпләр буенча гамәлгә ашырылырга тиеш.

Җир асты байлыкларыннан файдалану максатыннан төшү урыннары белән башка кисешкән урыннар, чиктәш урыннар һәм мондый юллардагы төшү урыннары арасындагы ераклык 200 метрдан да ким булмаска тиеш.

Туры һәм капма-каршы юнәлешләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында төшү урыннары ясалган урыннарда җирле әһәмияттәге автомобиль юлында күренүнең минималь ераклыгы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән юл өслеге күренү ераклыгыннан ким булмаска тиеш.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын эшләү һәм тормышка ашыру шартларында төшү урыннарын башка кисешү урыннарыннан, җирле әһәмиятттәге автомобиль юлына чиктәш урыннардан һәм әлеге юллардан төшү урыннарыннан азрак ераклыкта төзү рөхсәт ителә. Мондый чараларны эшләү, Башкарма комитет белән килештереп, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан башкарыла.

7. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлының бүлү полосасы чикләрендә юл сервисы объектларын урнаштыру территорияне планлаштыру документларына һәм Башкарма комитет белән төзелә торган юл сервисы объектын җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушу турында шартнамә нигезендә техник регламентлар таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырыла.

8. Юл сервисы объектларын җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына кушу хезмәтләрен күрсәткән өчен Башкарма комитеты белән төзелә торган

юл сервисы объектын җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушу турында шартнамә нигезендә түләү алына.

9. Юл сервисы объектын җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушу турында шартнамә төзегәндә Башкарма комитет мондый шартнамә төзи торган затларга җирле әһәмияттәге автомобиль юлын реконструкцияләү яисә аңа капиталь ремонт ясау турында һәм аларны гамәлгә ашыру вакытлары турында хәбәр итә.

10. Керү урыннарын, төшү урыннарын һәм чиктәш урыннарны, транспорт чараларын куеп тору урыннарын һәм туктап тору урыннарын, күчеш-тизлек полосаларын төзү, реконструкцияләү, аларга капиталь ремонт ясау, ремонт ясау һәм карап тоту юл сервисы объекты хуҗасы тарафыннан яисә аның исәбеннән гамәлгә ашырыла. Керү урыннарын, төшү урыннарын һәм чиктәш урыннарны, транспорт чараларын куеп тору һәм туктап тору урыннарын, күчеш-тизлек полосаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту юл хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр классификациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Юл сервисы объектларының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына кушылган урыннарын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау Башкарма комитетның язма ризалыгы булганда рөхсәт ителә. Бу ризалыкта юл сервисы объектларының хуҗалары тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

Төзелешкә рөхсәтсез, килешүнең әлеге пунктының икенче абзацында каралган ризалыксыз яисә мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләрне һәм шартларны бозып, юл сервисы объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны яки юл сервисы объектларының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына чиктәш урыннарны реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны гамәлгә ашыручы затлар Башкарма комитет таләбе буенча юл сервисы объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны яки юл сервисы объектларының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына чиктәш урыннарны реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны туктатырга, законсыз төзелгән корылмаларны, башка объектларны сүтәргә һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын башлангыч хәлгә китерергә тиеш.

11. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы «е» пунктчасы, 8 - 10 пунктларындагы таләпләр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына тоташа торган гомуми мәйданы 10 мең квадрат метрдан артык булган стационар сәүдә объектларына карата кулланыла. Күрсәтелгән нигезләмә 2017 елның 16 апреленә кадәр файдалануга тапшырылган 10 мең квадрат метрдан артык мәйданлы объектларга карата кулланылмый, моңа керү урыннарын, төшү урыннарын, чиктәш урыннарны, транспорт куеп тору һәм туктап тору урыннарын, күчеш-тизлек полосаларын карап тотуга таләпләр керми.

12. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору, аларны эксплуатацияләү мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан яисә алар исәбенә мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары белән Башкарма комитет төзелә торган шартнамә һәм төзелешкә рөхсәт (мондый инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителгән очракта) нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән шартнамәдә аларны салганда, күчергәндә, үзгәртеп корганда, эксплуатацияләгәндә мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар каралырга тиеш.

13. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан яисә алар хисабына мондый инженерлык коммуникацияләре салуны, күчерүне яисә үзгәртеп коруны проектлаганда Башкарма комитет мондый инженерлык коммуникацияләрен урнаштыруны язмача килештерә.

14. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору Башкарма комитетның язма рәвештә ризалыгы булганда һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бирелә торган төзелешкә рөхсәт (мондый инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителгән очракта) нигезендә гамәлгә ашырыла. Бу ризалыкта инженерлык коммуникацияләрен салганда, үзгәртеп корганда, күчереп йөрткәндә, эксплуатацияләгәндә мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

15. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлының бүлъ полосасы һәм (яисә) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору җирле әһәмияттәге автомобиль юлын, аның участокларын реконструкцияләүгә яисә капиталь ремонтлауга китергән очракта, мондый реконструкция, капиталь ремонт инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан яисә алар исәбеннән башкарыла.

16. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлын реконструкцияләгән очракта, күрсәтелгән объектларны, әлеге объектларга һәм (яисә) керү урыннары, төшү урыннары, чиктәш урыннарны үзгәртеп корган очракта, Башкарма комитет тарафыннан бирелгән язма ризалык булганда, мондый объектлар хуҗалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл буе полосалары, бүлү полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, үзгәртеп кору, күчерү һәм эксплуатацияләү, юл сервисы объектларын төзү һәм реконструкцияләү, чиктәш урыннарны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм эксплуатацияләү, реклама конструкцияләрен, мәгълүмат щитларын һәм күрсәткечләрне урнаштыру һәм эксплуатацияләү Таможня берлегенең 2011 елның 18 октябрендәге 827 номерлы карары белән расланган 014/2011 ТР ТС "Автомобиль юллары куркынычсызлыгы" Таможня

берлегенең Техник регламентында каралган таләпләрне, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы, экологик куркынычсызлык, автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү стандартлары һәм техник нормалары таләпләрен, башка норматив хокукый актлар таләпләрен (алга таба – стандартлар һәм техник нормалар таләпләрен) исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

18. Капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә мондый объектны урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителгән очракта, күрсәтелгән документларны раслаганчы, ул Башкарма комитет белән килештерелә. Бу ризалыкта үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш. Шул ук вакытта автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объектны төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык алу таләп ителми.

19. Автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документлары белән автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объект төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бирү турында яисә мондый объектны төзүне, реконструкцияләүне, территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамә Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә мондый объектны төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында яисә автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документларын килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка җибәрелә.
Мондый объектны төзүне, реконструкцияләүне, территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту турында хәбәрнамәдә мондый баш тартуның барлык сәбәпләре күрсәтелергә тиеш.

20. Автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә объект төзүне, реконструкцияләүне, автомобиль юлларының юл буе полосасы чикләрендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту түбәндәге нигезләрдә рөхсәт ителә:

1) объектны төзү, реконструкцияләү автомобиль юлында күрү мөмкинлеген һәм юл хәрәкәте куркынычсызлыгының башка шартларын начарайтуга китерәчәк;

2) объектны төзү, реконструкцияләү автомобиль юлын һәм аның составына керә торган юл корылмаларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкарып булмауга китерә;

3) территориаль планлаштыруның расланган документларында һәм (яисә) территорияне планлаштыру документларында әлеге реконструкцияләү каралган очракта, объектны төзү, реконструкцияләү автомобиль юлын реконструкцияләүнең мөмкин булмавына китерәчәк.

21. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында урнашкан җир кишәрлекләрендә, әлеге полосалардан

читтә урнашкан, әмма җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында аларга махсус керү урыны (керү урыннары, төшү урыннары, чиктәш урыннар) булуны таләп итүче җир кишәрлекләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә объектларны урнаштыруга язмача ризалык алу өчен һәм объектны җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушуга килешү төзү өчен бу максатлар өчен җир кишәрлеге алырга яки объектны элек бүлеп бирелгән җир кишәрлегенә урнаштырырга теләгән кеше Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1:10000 масштабында районның планлаштырыла торган объектны урнаштыру план-картография материалы, җир кадастры хезмәтенең зәңгәр мөһере белән расланган, планлаштырылган объектны урнаштыру урынын һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары белән кисешү урыннарын күрсәтеп;

1:1000 яки 1:500 масштабындагы участок планы, якындагы объектларны һәм инженерлык коммуникацияләрен күрсәтеп, автомобиль юлына бәйләп, аңа планлаштырылган объектны төшереп;

1:200 масштабында биналарның планнары, киселеше, файдаланыла торган эшкәртү материаллары тасвирламасы белән фасадның төсле бизәлеше, объектның гомуми күренеше;

күчеш-тизлек полосаларын күрсәтеп, тоташкан урында юл төшү урыны белән тоташканда түгәрәкләнү радиусы чикләрендә транзит автотранспортын хәрәкәтен оештыру һәм аның куркынычсызлыгы схемасы;

автомобиль юлының буй һәм аркылы профильләре;

юл сервисы объектын төзүнең эш проекты яисә проект документациясе.

22. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен урнаштыруга язма формада ризалык алу өчен мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

эшләр җитештерү проекты;

автомобиль юллары аша кучешләрнең 1:500 масштабында планнары һәм 1:100 масштабында профильләре;

коммуникацияләр салу урынында имин шартлар тәэмин итү чаралары исемлеге (техниканы туплау схемасын, эшләрне башкару вакытына юл билгеләрен һәм вакытлыча киртәләрнең куелуын, техника өчен төшү урыннарын күрсәтергә).

23. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында урнашкан җир кишәрлекләрендә, әлеге полосалардан читтә урнашкан, әмма җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосасында һәм юл буе полосасында аларга махсус керү урыны (керү урыннары, төшү урыннары, чиктәш урыннар) булуны таләп итүче җир кишәрлекләрендә объектларны урнаштыруга язмача ризалык бирү кызыксынган затның мөрәҗәгатен теркәгәннән соң 30 календарь көн эчендә Башкарма комитетның җаваплы хезмәткәре карап чыкканнан һәм җирле

әһәмияттәге автомобиль юлының баланста тотучысы белән килештергәннән соң гамәлгә ашырыла. Объектларны планлаштырылган урында урнаштыру өчен техник мөмкинлек булмаганда, Башкарма комитет мөрәҗәгать итүчегә, кызыксынучы затның мөрәҗәгатен теркәгән көннән алып 30 календарь көн эчендә объектны урнаштыруга язма рәвештә ризалык бирүдән дәлилле баш тарту кәгазен бирә.

24. Объектны файдалануга тапшыру Башкарма комитетның җаваплы хезмәткәрләре катнашында кабул итү комиссиясе тарафыннан башкарыла. Кабул итү комиссиясенең эшчәнлек тәртибе һәм составы Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

25. Юл сервисы объектын эксплуатациягә кертү юл сервисы объекты милекчесенең Башкарма комитет белән төзелгән объектны җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушу турында шартнамәсе булмаган очракта рөхсәт ителми.

26. Инженерлык коммуникацияләрен салуга,үзгәртеп коруга һәм күчерүгә; капиталь төзелеш объектларын, юл сервисы объектларын, мәгълүмат конструкцияләрен һәм күрсәткечләрен урнаштыруга, юл сервисы объектларын җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына чиктәш урыннарын реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга ризалык бирү Башкарма комитет тарафыннан хезмәт күрсәтүләр турында шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

27. Мәҗбүри техник таләпләрне һәм шартларны үз эченә алган ризалыкны әзерләү һәм бирү Башкарма комитет тарафыннан хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

28. Юл сервисы объектын җирле әһәмияттәге автомобиль юлына кушу турында шартнамә төзү кызыксынган зат мөрәҗәгатен теркәгән көннән алып 30 календарь көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

29. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә объектларны проектлауга, төзүгә, урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә бирелгән техник шартларның үтәлешен тикшерү Башкарма комитет тарафыннан кварталга бер тапкыр, ә җир асты һәм җир өсте инженерлык коммуникацияләрен тикшерү елга бер тапкыр башкарыла.

Объектларны проектлауга, төзүгә һәм эксплуатацияләүгә техник шартлар таләпләре бозылган очракта, ачыкланган хокук бозуларны стандартлар һәм техник нормалар таләпләрендә билгеләнгән вакытларда бетерү тикшерелә.

30. Бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, хуҗалары, файдаланучылары һәм арендага алучылары түбәндәгеләрне эшләргә хокуклы:

а) әлеге Тәртип һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

б) аларга бирелгән җир кишәрлекләрендә әлеге Тәртип һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән рөхсәт ителгән объектлар төзергә;

в) җирле әһәмияттәге автомобиль юлын ремонтлау яисә реконструкцияләү турында мәгълүмат алырга.

31. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, хуҗалары, файдаланучылары һәм арендага алучылары түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

а) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә җирләрне саклау кагыйдәләрен һәм алардан файдалану режимын, шулай ук экологик куркынычсызлык нормаларын үтәргә;

б) автомобиль юлларына зыян килүгә яисә автомобиль юлларына зыян китерүче яки транспорт чаралары һәм (яки) җәяүлеләр хәрәкәтенә комачаулаучы башка гамәлләр кылуга юл куймаска, автомобиль юлыннан файдалану шартларын һәм юл хәрәкәте иминлеген үтәргә;

в) үз карамагындагы җир кишәрлекләренә бүлү полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә җирләрне куллануны контрольдә тотарга вәкаләтле вазыйфаи затларны кертүне тәэмин итәргә, шулай ук аларга бирелгән таләпләрне вакытында үтәргә;

г) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлү полосалары чикләрендә, шул исәптән автомобиль юлларының йөрү өлешендә транспорт чаралары тәгәрмәчләренең юл өслеге белән берегүен киметүгә йогынты ясарга мөмкин булган матдәләр куллануга бәйле, шулай ук янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмичә, эшләр башкаруга юл куймаска;

д) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын, аларның бүлү полосаларын һәм юл буе полосаларын куллануны чикләүгә, шулай ук аларның сакланышын тәэмин итүгә карата Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймаска.